Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге Сәет авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«31» октябрь, 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Сәмәкәй авыл җирлеге Сәет авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2021 елда яшәү урыны буенча Сәмәкәй авыл җирлеге Сәет авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-балалар мәйданчыгын төзекләндерү;

2. «2019 елның 9 ноябрендә Сәет авылы гражданнарының җыены нәтиҗәләре буенча 2020 елда җыелган хисабына түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә үзгәртергә»

- «Сәет авылы зиратына керү юлында арка газүткәргече урнаштыру»ны
- « - Сәет авылында агачларын кисү»гә

3. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәет авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Сәет авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы И.М.Усманов